СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2021 Әгерҗе шәһәре № 8-4

Әгерҗе муниципаль районы Советының 2016 елның 09 февралендәге 6-8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 12 февралендәге ПУ-132 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әгерҗе муниципаль районы Советының 2016 елның 09 февралендәге 6-8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1.1. 1.5 пунктта «, шулай ук кәгазьдә» сүзләрен төшереп калдырырга;
   1.2. 2.1 пунктта «һәм кәгазьдә» сүзләрен төшереп калдырырга;
   1.3. 2.2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
   1.4. 2.3 пунктында «Департамент» сүзен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (алга таба - Департамент)» сүзләренә алмаштырырга;
   1.5. 2.6 пунктының икенче абзацында «атасының исеме» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;
   1.6. 4 кисәкне яңа редакциядә бәян итәргә:

«IV. Муниципаль хезмәткәрләр реестрларыннан белешмәләр тапшыру һәм реестрларны саклау.

4.1. Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре реестрыннан белешмәләр «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 23 октябрендәге ПУ-431 номерлы Указы нигезендә тапшырыла.

4.2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре реестры һәм аларга үзгәрешләр, үзендә булган мәгълүматны рөхсәтсез файдаланудан, юкка чыгарудан, модификацияләүдән, блоклаудан, күчерүдән, күрсәтүдән, таратудан, шулай ук башка хокуксыз гамәлләрдән яклауны тәэмин итеп, Мәгълүмати системада саклана.»

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының әлеге карар үз көченә кергәнче кәгазь чыганакларда төзелгән муниципаль хезмәткәрләре реестрлары аларны төзегән көннән алып 5 ел дәвамында (катгый хисап документлары буларак) аларга санкцияләнмәгән керү мөмкинлеген булдырмый торган режимда саклана, шуннан соң Россия Федерациясе законнары нигезендә архивка саклауга тапшырыла".

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе — А.Р. Вәлиев